Актаныш муниципаль районы Яңа Әлем төп гомуми  белем бирү мәктәбе

Математика укытучыларының район семинары

3 класста математикадан ачык дәрес

1-1000 саннарының язма нумерациясы . Белемнәрне ныгыту.

1 квалификацион категорияле башлангыч сыйныфлар укытучысы
Мәрданова Фәния Дөфәк кызы.

2024 ел

Тема: 1-1000 саннарының язма нумерациясы . Белемнәрне ныгыту .

Максат: Өчурынлы саннарны  дөрес язу, уку күнекмәләрен ныгыту.

Көтелгән нәтиҗәләр:

Укучыларның өчурынлы саннарны дөрес әйтү һәм дөрес язу күнекмәләрен формалаштыру, мәсьәләләр чишү, фикерләү сәләтен,финанс грамоталылыгын үстерү;

Дәреснең җиһазланышы:

Проектор, разрядлар һәм класслар таблицасы , магнит цифрлары, төркемнәрдә эшләү өчен карточкалар, үзбәя өчен карточкалар.

**1. Оештыру моменты. Кунакларны каршы алу һәм сәламләү.**

Укучылар:

-Исәнмесез! Хәерле иртә, хөрмәтле укытучылар! Безнең сыйныфка рәхим итегез! (Балалар эш урыннарына утыралар)

Укытучы:

(Уңай атмосфера булдыру һәм дәресне башлап җибәрү)

-Илдә кояш,

Җирдә кояш,

Йөздә кояш, күздә кояш.

Көндәгечә, көлә кояш,

Әмма бүген үзгә кояш.

-Укучылар, уйлыйк әле, татар дөньясында бүгенге көн нинди бәйрәм буларак билгеләп үтелә?

Балалар:

-Бүген- Туган тел көне.

-Балалар, хөрмәтле кунаклар, бүгенге матур көн кебек, барыгызга да яхшы кәефләр, көнегезнең уңышлы узуын телим!

-Дәресебезне башлап җибәрик!

**2.Белемнәрне актуальләштерү**

**Саннарны 3 төркемгә бүлик:**

**1)**1, 12, 500, 3, 34, 600, 5, 75, 900, 4, 98, 100,7.

**2)** -дәфтәрләрдә араларында бер шакмак калдырып 4, 5, 6 цифрларын язу;

-шушы цифрлар ярдәмендә мөмкин булган барлык өчурынлы саннарны язырга;

-язылган саннарны укыйлар (465, 456, 464, 546, 654, 645)

-Укучылар, хәзер язылган саннарны тикшереп чыгыгыз.

(экранга карап тикшерәләр)

-шушы саннар арасында иң кечкенә санны әйтегез (456)

-язылган саннар арасындагы иң зур санны табыгыз (654)

**3)-**100 дән 1000 гә кадәр йөзәрләп санау (чылбыр буенча эш):

-1000 нән 100 гә кадәр йөзәрләп санау;

**4)**- 7 йөз 3 дис 5 бер тән торган санны әйтегез;

-йөзләре 6 , дистәләре һәм берәмлекләре бер үк цифр белән языла торган өчурынлы саннарны әйтергә ( фронталь сорау)

(611, 622, 633, 644, 655, 666, 677, 688, 699)

**5)** Язылышында бер үк цифрлар кулланыла торган өчурынлы саннарны тактага язу

( 111, 222, 333, 444,555, 666, 777, 888, 999)

**3. Тема буенча эш**.

**1)**-төркемнәрдә эш оештыру

**1 төркемгә бирем**:

Мәсьәлә

Безнең гаиләгә кибеттән 60 сумга шоколад, 100 сумга уенчык машина, әнигә 500 сумга күлмәк сатып аласы бар. Шушы товар өчен акча янчыгыннан нинди акчалар белән кассага түли алабыз?

**2 төркемгә бирем :**

Мәсьәлә

Мәктәптә уздырылган ярминкәдә безнең сыйныф 150 сумга беләзек, 250 сумга пироженое, 100 сумлык кишер сатты? Безгә сатып алучылар биргән акчаларны ничек дөрес итеп акчалар арасыннан җыярга мөмкин?

**3 төркемгә бирем:**

Мәсьәлә

Әни белән базарда без 300 сумлык алма, 200 сумлык помидор, 150 сумлык кыяр саттык. Безнең гаиләбезгә керем булып кергән акчаларны акчалар арасыннан ничек аерып алырга мөмкин?

2) төркем җитәкчеләре җавап бирәләр укыйлар;

**4.Күнекмәләрне ныгыту.**

Дәреслек буенча эш.

№1, № 2 (46 бит) телдән үтәү;

**ФИЗМИНУТКА** ( “Чебиләр зарядкасы”җырлап бию)

4)№3 (46 бит) тактада һәм дәфтәрдә эш)

5)№4 мәсьәләне эчтән, кычкырып уку ;

- мәсьәләнең эчтәлеген анализлау;

-мөстәкыйль чишү;

- такта янында чишеп тикшерү;

-№5 карточкалардагы аңлатмалар буенча мәсьәләләр төзү;

**5.Рефлексия.**

(экранда күрсәтелә)

-Дәрес сезгә кайсы ягы белән файдалы булды?

-Сезгә нинди күнекмәләрне ныгыту буенча эшлисе бар?

- Җөмләләрне дәвам итәбез:

-Бүгенге дәрестә мин...

-Миңа кызыклы булган эш төрләре...

-Миңа дәрестә очраган кыенлыклар...

-Дәрес миңа киләчәгем өчен...

Укытучы:

-Укучылар, һәрберебез үзегезнең дәрестәге эшчәнлекне бәялик.

**6**.Һәр бала карточкалар ярдәмендә үз эшчәнлегенә бәя бирә.

**7**.Өй эше.№7,№8, 46 бит.

**8**.-Дәрес өчен зур рәхмәт, укучылар.Миңа сезнең белән дәрестә эшләве бик кызыклы булды. Алган белемнәрегез киләчәктә файдалы булсын.

Дәрестә кулланылган материал: М. И.Моро.Математика дәреслеге , 3 сыйныф, 2 нче кисәк.

Җиһаз: Интернет материаллары,күрсәтмәлелек өчен интернет материаллары, таблицалар, аудиоязма,презентация.